ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.03.2021 с.Старое Дрожжаное № 110

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 9 сентябрендәге 679 нчы номерлы карары (2021елның 21 гыйнварындагы 15 нче номерлы редакциясендә) белән расланган, мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.1. Әлеге Тәртип җан башына уртача кереме 20,0 мең сумга кадәр булган гаиләләргә, мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында, балаларны карап торган һәм караган өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүнең бер өлешенә өстәмә компенсация билгеләү, түләү шартларын һәм тәртибен билгели (алга таба - компенсация).»;

түбәндәге эчтәлекле 1.2.1 пункт өстәргә:

«1.2.1. Җан башына уртача кереме 20,0 мең сумга кадәр булган гаиләләргә, мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм карап торган өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүнең бер өлешенә өстәмә компенсация билгеләгәндә, гаиләнең җан башына уртача кереме, аны билгеләү турында гариза бирү ае алдындагы алты календарь айга кадәрге соңгы 12 календарь айда гаилә әгъзаларының айлык керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә.»;

2.1 пунктындагы «b» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«b) компенсация билгеләү турында гариза биргән ай алдыннан алты календарь айга кадәрге 12 календарь айда гаилә әгъзаларының керемнәре турында документлар;».

2. Әлеге карар 2021 елның 1 апреленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов